**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«30» октябрь, 2020 ел № 1593

2021 елга Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы гомуми
белем бирү оешмаларының норматив
чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 12 декабрендәге 1340 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карары белән Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2021 елга кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль оешмаларының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатлары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар;

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлеге финанс-бюджет палатасында түбәндәгеләр раслаган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2020 елның 26 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.С.Шәйхисламов

Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы муниципаль
оешмалары башкарма комитеты
җитәкчесе карары белән расланды
«__» ______ _____ 20___ № ___

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга, сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | Авыл җирлеге | 94213 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | Авыл җирлеге | 143701 |